СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.10. с. Шеланга

Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге  Шилангы авылы торак пункты территориясенең бер өлешендәгражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Шилангы җирлеге Уставы нигезендә,   Шилангы авылы торак пунктының бер өлеше халкы төркеменең инициативасын карап чыгып,

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге  Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясенең бер өлеше гражданнарыннан җыелган үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 6 ноябренә билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда  Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Шилангы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5555 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

- Кооператив урамында 2 данә кое урнаштырып, 200 м озынлыктагы сууткәргеч төзү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Шилангы авылы, Кооператив ур., 6 нчы йорт янында 16.00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров